КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 декабрь г.Казань № 1338

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 ноябрь, 1230 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 ноябрь, 1230 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибенә, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яки Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты тарафыннан гамәлгә куючы функцияләре һәм вәкаләтләре гамәлгә ашырыла торган түбәндәге дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба шул ук эзлеклелектә – Учреждение, субсидияләр) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү механизмын гамәлгә кертә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларын рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин